**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

# КАРАР

«01» октябрь, 2025 ел

№ 721-п

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучылар һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләргә өстәмә социаль ярдәм чаралары турында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучылар һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләргә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, район Уставының 85 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2024 елның 5 декабрендәге 67 номерлы «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 елларның план чорына бюджеты турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның түбәндәге категорияләре өчен ике тапкыр бушлай кайнар туклану билгеләргә:

- Питрәч районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге хезмәткәрләренең, Питрәч районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлегенең федераль дәүләт граждан хезмәткәрләренең, Питрәч районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге эшчеләренең балалары өчен (5-11 сыйныфлардагы бер укучыга туклануга субсидия күләме - 64,47 сум көненә; «лицей» статусына ия мәгариф учреждениеләрендә 5-11 сыйныфлардагы бер укучыга туклануга субсидия күләме - 63,00 сум көненә).

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәктәпкәчә учреждениеләренә (балалар бакчаларына) йөрүче балаларны карау һәм тәрбияләү өчен түләүдән азат итәргә:

- Питрәч районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге хезмәткәрләренең, Питрәч районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлегенең

федераль дәүләт граждан хезмәткәрләренең, Питрәч районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге эшчеләренең балаларының ата-аналарын.

3. Расларга:

- Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәне (1 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләргә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәне (2 нче кушымта).

4. Финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1-2 пунктларында күрсәтелгән чыгымнарны өстәмә бүлеп бирелгән акчалар хисабына билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Мәгариф бүлеге» МБУ тәэмин итә:

1) муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга туклану оештыру турында мәгълүматны Социаль өлкәдә Бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформаны (алга таба - БЦП) куллану аша, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә, һәм БЦП операторы билгеләгән форматларга туры китереп, юнәлтүне;

2) БЦП куллану аша, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә, һәм БЦП операторы билгеләгән форматларга туры китереп, мәгълүмат алуны.

6. Әлеге карарның гамәле 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

7. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 1 июлендәге 376-п номерлы «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучылар һәм муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләргә өстәмә социаль ярдәм чаралары турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында http://www.pestreci.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.А. Харитоновага йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Р. Дәүләтханов

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитетының
__. __. 2025 ел, № ___ карарына

## Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмә

### 1 нче бүлек. Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга (алга таба - укучылар) өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибе турындагы әлеге нигезләмә «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, район Уставының 85 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2024 елның 5 декабрендәге 67 номерлы «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 елларның план чорына бюджеты турында» карары нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучылар өчен бушлай туклану оештыру рәвешендә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибен билгели.

Ике тапкыр бушлай кайнар туклану бирелә:

- Питрәч районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге хезмәткәрләренең, Питрәч районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлегенең федераль дәүләт граждан хезмәткәрләренең, Питрәч районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге эшчеләренең балалары өчен.
- Бушлай ике тапкыр тукلануны махсус медицина күрсәтмәләре буенча өйдә укучыларга (инвалид балалар, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен) ике тапкыр туклануның бәясен акчалата компенсацияләү белән алмаштыру тәэмин ителә.

### 2 нче бүлек. Муниципаль гомуми белем бирү оешмасында туклануны оештыру

1. Муниципаль гомуми белем бирү оешмасында укучыларга туклану оештыру өчен туклану оештыру комиссиясе төзелә, аның составы гомуми белем бирү оешмасы директоры боерыгы белән раслана (алга таба – комиссия). Комиссия составына гомуми мәктәп ата-аналар комитеты вәкиле кертелә. Комиссия әгъзаларының берсе укучыларга туклану оештыру өчен җаваплы итеп билгеләнә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны биш кешедән дә ким түгел.
2. Комиссия укучылар исемлеген ай саен агымдагы айның 15 числосына кадәр киләсе айга раслый.
3. Гомуми белем бирү оешмасы директоры тәэмин итә:

1) гамәлдәге законнар һәм бюджет чараларын максатчан файдалану нигезендә укучыларга кайнар туклану оештыруны, бушлай кайнар туклану алучы укучыларның фактик санын исәпкә алуны;

2) өйдә укучы инвалид балалар һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен ике тапкыр туклану бәясен акча эквивалентында компенсацияләүне оештыруны;

3) ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) документлар кабул итү буенча эшне оештыруны.

4. Бушлай кайнар туклану бирү турында гаризаларны кабул итү электрон рәвештә (гомуми белем бирү оешмасының электрон почтасына) яки шәхсән гомуми белем бирү оешмасында укучы укый торган урында гамәлгә ашырыла.

5. Бушлай туклану Питрәч районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге хезмәткәренең, федераль дәүләт граждан хезмәткәренең, Питрәч районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге эшчесенең эш урыныннан белешмә нигезендә бирелә.

6. Укучыларга туклану оештыру өчен җаваплы белем бирү оешмасына укучы килгәннән соң 10 эш көне эчендә «Татарстан Республикасы Электрон мәгариф» дәүләт мәгълүмат системасында укучының шәхси эшен тутыру буенча эшне оештыруны тәэмин итә, укучыны мәктәп укучысы картасын ясау реестрына кертү өчен кирәкле мәгълүматларны кертә (фамилия, исем, әтисенең исеме, туган көне, җенесе, туу турындагы таныклык мәгълүматлары (бирелү иле, РФ субъекты, сериясе, номеры һәм бирелү датасы), паспорт (булганда), фотография, «Картага фото» аерылган фрагмент яки фотога төшүдән баш тартканда контур).

7. Ташламаны бирү өчен ата-аналарга (законлы вәкилләргә) - хезмәткәрләргә, федераль дәүләт граждан хезмәткәрләренә, Питрәч районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге эшчеләренә һәр алты айдан ташламаны раслаучы документлар күчермәләрен яңартырга кирәк.

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитетының
__. __. 2025 ел, № ___ карарына

**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләргә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмә**

1. Питрәч муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләргә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибе турындагы әлеге нигезләмә «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, район Уставының 85 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2024 елның 5 декабрендәге 67 номерлы «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 елларның план чорына бюджеты турында» карары нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре тәрбияләнүчеләре - балаларны карау һәм тәрбияләү өчен түләүдән азат итү рәвешендә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибен билгели.
2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре тәрбияләнүчеләре - балаларны карау һәм тәрбияләү өчен түләүдән азат итү рәвешендә өстәмә социаль ярдәм чаралары Питрәч районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге хезмәткәрләренә, Питрәч районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлегенең федераль дәүләт граждан хезмәткәрләренә, Питрәч районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге эшчеләренә бирелә.
3. Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесе тәэмин итә:

1) әлеге нигезләмәнең 2 нче пунктында күрсәтелгән балаларны карау һәм тәрбияләүне;

2) ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) документлар кабул итү буенча эшне оештыруны.

4. Баланы карау һәм тәрбияләү өчен түләүдән азат итү турында гаризаларны кабул итү электрон рәвештә (муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең электрон почтасына) яки шәхсән муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә гамәлгә ашырыла.
5. Балаларны карау һәм тәрбияләү өчен түләүдән азат итү Татарстан Республикасы Питрәч районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге хезмәткәренең, федераль дәүләт граждан хезмәткәренең, Питрәч районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге эшчесенең эш урыныннан белешмәсе нигезендә бирелә.
6. Питрәч районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге хезмәткәрләренә, Питрәч районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлегенең федераль дәүләт граждан хезмәткәрләренә, Питрәч районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге эшчеләренә - ата-аналарга (законлы вәкилләргә) ташламаны бирү өчен һәр алты айдан ташламаны раслаучы документлар күчермәләрен яңартырга кирәк.